РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

18 декабрь 2017 ел № 15

Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге
территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны
һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм
ысулларын билгеләү һәм янгын сүндерү
максатларында су алу өчен шартлар тудыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 20 сентябрендәге 947 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясендә торак пунктларның янгынга каршы торучанлыгын арттыру максатларында, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләрендә, якындагы корылмаларга кадәр 50 метр ара ераклыкта, җилсез һавада, һәм чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материаллар яки эшләнмәләрне яндыруны даими контрольдә тоту шартларыннан тыш, учаклар ягу, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материаллар яки әйберләрне яндыру тыела.

2. Янгын сүндерү максатларында елның теләсә кайсы вакытында авыл торак пунктларында алар янындагы территорияләрдә урнашкан тышкы су чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудырырга.

3. Объект территориясендә яисә аның янында (200 метр радиуста) табигый яки ясалма су чишмәләре (елгалар, күлләр, бассейннар, градирни h. б.) янгын сүндерү автомобильләре урнаштыру һәм елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен 12х12 метрдан да ким булмаган зурлыктагы мәйданчыклар (пирслар) белән янгын сүндерү

машиналары урнаштыру һәм елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен. мәйданчыклар (пирслар) белән подъездларны төзекләндерергә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим кертелгән чорда үз гамәлдә түгел.

5. Әлеге карар имзалангач законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырылып чыгарылырга тиеш, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырыла (http://buinsk.tatarstan.ru).

Түбән Наратбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең А.С. Җәләлов